ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» 10 2023 г. № 257

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла һәм гамәлгә ашыру планлаштырыла торган инвестиция проектларына «бер тәрәзә» принцибы буенча булышлык итү регламентын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында » 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә инвестиция активлыгын арттыру һәм инвестиция эшчәнлеген үстерү өчен уңай шартлар тудыру, муниципаль берәмлектә гамәлгә ашырыла торган (гамәлгә ашыру планлаштырыла торган) инвестиция проектлары буенча белешмәләрне исәпкә алуны системалаштыру максатларында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырылучы һәм гамәлгә ашыру планлаштырыла торган инвестиция проектларына «бер тәрәзә» принцибы буенча булышлык итү регламентын расларга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет - ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Балтач муниципаль
район башлыгы Р.Р.Нотфуллин